РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«24» март 2025ел

№ 51

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 декабрендәге 171 номерлы «Муниципаль мөлкәтне сәүдәләр үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 28 декабрендәге 521-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 декабрендәге 171 номерлы «Муниципаль мөлкәтне сәүдәләр үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Муниципаль мөлкәтне сәүдәләр үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

А) түбәндәге эчтәлекле 2.3.5 пункт белән тулыландырырга:

«2.3.5. Хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү очраклары һәм тәртибе каралмаган.»;

Б) 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүмат.

Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 52 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы һәм аларны күрсәткән өчен түләүнең иң чик күләмен билгеләүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» карары нигезендә, муниципаль

милектәге су объектларын су белән файдалану шартнамәсе яисә су объектын файдалануга бирү турында карар нигезендә файдалануга тапшырганда кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүләр таләп ителми;

в) 2.5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе гражданы паспорты йә шәхесне таныклаучы башка документ Россия Федерациясе законнары нигезендә (бердәм, республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми) яисә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарда, "Физик затларны биометрик персональ белешмәләрдән файдаланып идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне гамәлгә ашыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында" 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9,10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып күпфункцияле үзәкләрдә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән;».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин